**Шәһәр күләмендә физика фәненнән татар телендә үткәрелә торган олимпиаданың йомгаклау этабы биремнәре**

**2024/2025 уку елы**

**11 нче сыйныф**

**Эш вакыты – 150 мин.**
**Гомуми балл – 50**

**1.** 1 кг массалы йөкне авышлык почмагы $30^0$ булган авыш яссылыкка салганнар. Йөк һәм яссылык арасындагы ышкылу коэффициенты 0,2 гә тигез. Йөкне авыш яссылык өслегендә тотып торучы көчне $F$ табыгыз.

**2.** Электрон, 2000 В лы потенциаллар аермасын үтеп, индукциясе $15 \cdot 10^{-5}$ Тл булган магнит кырына очып керә һәм 1 м радиуслы әйләнә буенча хәрәкәт итә башлый. Электрон корылмасының массасына чагыштырмасын табыгыз.

**3.** Индукциясе 0,2 Тл булган вертикаль магнит кырында юка җепкә 2м озынлыгындагы үткәргеч элеп куелган. Үткәргеч аша 2 А зурлыклы ток үткәрелсә, җеп вертикальдән $45^0$ ка тайпылачак. Үткәргечнең массасын табыгыз.

**4.** Данил үз куллары белән электроплитканы җыярга булган. Егәрлеге 400 Вт ка тигез булган җылыту элементының спирален ясау өчен ул нихром чыбык чорналган кәтүкне алган. Әгәр чыбыкның аркылы кисеме мәйданы 0,2 $мм^2$, ә челтәрдәге көчәнеш 220 В га тигез булса, малайга кәтүктән нинди озынлыктагы чыбыкны кисеп алырга кирәк булыр? Нихромның чагыштырма электр каршылыгы 1,1 $(Ом \cdot мм^2)/м$.

**5.** Массасы 400 г га тигез булган борысны горизонталь рәвештә урнашкан пружина ярдәмендә горизонталь өслек буйлап 4 $м/с^2$ тизләнеш белән тарталар. Хәрәкәт иткәндә пружинаның озынлыгы 2 см булса, аның катылыгы күпме була? Борыс белән горизонталь өслек арасындагы ышкылу коэффициенты 0,02. Борысның тизләнеше аның хәрәкәте юнәлешендә. Һаваның каршылыгы исәпкә алынмый.